ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ
№ 1–2
18 февраль, 2023 ел
РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ОСТА КУЛЛАР
Ул талчыбыктан матурлык тудыра
> 2

ТОРМЫШНЫ ЯРАТЫП
Хиффә әби 88 яшьтә чана шуа
> 6

ҖИР КЕШЕСЕ
Эшләгән кешене хөрмәт итәләр
> 7

ТУЛЫ БӘХЕТ

Матур пар

Сөйкемле, тыйнак, ягымлы, рәхим-шәфкатьле Рәисә апа белән жор телле, энергиясе ташып торган, дөнья дилбегәсен әле дә кулында нык тотучы Мөбин абый Кәримуллиннар – тырыш хезмәтләре белән танылган, бәхетне туган җирдә тапкан кешеләр. Алар бу көннәрдә бриллиант туйларын бәйрәм итә.

Дүрт елга якын солдат шулпасы чөмереп кайткан, кызларның һушын алырдай чибәр егетнең Хороший Ключ авылы гүзәлен – Рәисәне алып кайтканда, кызга әле 17 яшь тә тулмаган була. «Мин яшь бит әле», – дип кияүгә чыгарга карышкан кызга булачак каенанасы: «Өч кызым да кечкенә, бергәләп үсәрсез», – ди. Моннан 60 ел элек әнә шулай башлана Кәримуллиннарның гаилә тарихы.

Өч ел бергә яшәгәч, бабаларының нигезенә күченеп, иркен йорт төзи алар. Рәисә апа 37 ел фермада сыер сава. Өч чакырылышта район Советы депутаты булып сайлана, «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

Мөбин абый башта шофер, соңыннан амбар, ферма мөдире булып эшли. Ташчы, балта остасы булуын искә алып, колхозның төзүчеләр бригадасына җитәкче итеп куялар үзен. 47 ел колхозда эшләгән Мөбин абый, пенсиягә чыкканчы ук, тагын бик зур вазыйфа башкара: дин юлында хезмәт куя. Башта мәзин, аннары ун ел имам-хатыйп була. Рәисә апаның дин юлында йөрүенә дә утыз елдан артык. Башта дини гыйлемне үзе өйрәнә, аннары шәкертләрне укыта. Мәчеткә дин сабагы өйрәнергә өлкәннәр дә, балалар да бик теләп йөри. Әлеге парга динебезнең бишенче баганасы булган хаҗ гамәлен үтәү бәхете дә елмайган.

«Авылыбызда иң үрнәк гаиләләрнең берсе – Кәримуллиннар», – ди зур ихтирам-хөрмәт белән кырындылылар.

> 4

Ватан хакына

Бергә булганда, җиңелмәс көч без

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) советы хәбәр иткәнчә, өлкәннәр Украинадагы хәрбиләребезгә гуманитар ярдәм күрсәтүдә актив катнаша. Район һәм шәһәр оешмалары рәисләре катнашында узган онлайн чарада әнә шул хакта сөйләштеләр.

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков чыгышыннан аңлашылганча, хәзерге вакытта республикада солдатларга гуманитар ярдәм оештыру буенча 84 пункт эшли. Шуның 20се – Казанда. Ярдәм үзәкләштерелгән төстә республиканың ике складыннан китерелә. Махсус хәрби операция башланганнан бирле фронтка 900 мең тоннадан артык йөк озатылган. Шулай ук мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә зур ярдәм күрсәтелә. Бу эшкә Татарстанның барлык муниципаль районнары – бизнес вәкилләре, иҗтимагый оешмалар һәм гади кешеләр кушылган.

Казан шәһәре ветераннар оешмасы рәисе Гүзәл Стрекалова Татарстан башкаласында өлкәннәр арасында әлеге эшнең ничек оештырылуы турында сөйләде. «Бергә булганда, җиңелмәс көч без» дигән гыйбарәне күз уңында тотып эшлибез, – дип билгеләп үтте Казан ветераннары җитәкчесе. – Барлык 210 башлангыч оешма активистлары эшкә керeште. Бик күп эшләнелә, барысын да массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртып барырга тырышабыз. Башта безгә методик кулланмалар җитмәде. Хәзер инде фронтка кирәкле әйберләрнең тулы исемлеге бар. Изге күңелле кешеләребез советка хәрбиләр өчен кирәкле әйберләр китерә. Без барысын да теркибез һәм фронтка озату өчен әзерләп куябыз».

Казан шәһәр советы «Игелекле Казан» оешмасы белән бер бинада урнашкан. Анда, тиешле адреслар буенча гуманитар ярдәмне алып, үз автомобильләрендә советка китереп куючы волонтерлар төркеме эшли. Казан активистлары да, мондый мөмкинлектән файдаланып, телефоннан алынган заявкаларны тапшыра. Гүзәл Стрекалова әйтүенчә, иң элек маскировка челтәре үрү өчен материал бик кирәк. Ветераннар аны үрүдә дә актив катнаша.

Ахыры 5 нче биттә >

ОСТАЛАР БАРЫНДА ЮГАЛМЫЙБЫЗ

Талчыбык! Ул элекке заманда һәр татар гаиләсенең матчасына кыстырылган булыр иде. Кирәкмәгән гамәл кылган, «тел озайтып» карышып торган баланы тәрбияләү чарасы булуы белән дә урта һәм өлкән буынга яхшы таныш ул сыек талчыбыгы. Кан чыгармый, кара яндырмый – чыжлап кына тискәренең сыртына төшә – бала гомерлек сабагын ала. Бер тапкыр тал чыбыгының «тәмен татыган» бала кабат-кабат бер үк тырмага басып хаталанмый. Әнә шул рәвешле үскән буын күпчелек вакыт ата-ана кадерен белүчән, эш яратучан булды.

Тал чыбыгыннан ясалган җыйнак, матур тырыс тотып урманга җиләккә йөрүләр – балачак хатирәсе. Хәтта елга-күлгә бай якларда балык сөзү өчен дә киң авызлы җәтмә-кәрзин кулланганнар элек. Саный китсәң... Каз оялары үзе генә дә ни тора! Сиртмәле караватт астында йомырка җылытып утыручы ана каз өчен ул уңайлы, экологик өй ролен үтәде. Тавык ояларын да талчыбыктан үрәләр иде безнең якта. Күз алдымда тора читән белән әйләндереп алынган бәрәңге бакчалары! Аның киртәсенә элеп куелган таш чүлмәкләр. И-и гомерләр, дип әйтерсең дә шул. Читәнне – профнастил, табак-савыт, кухня кирәк-ярагын тулысынча диярлек пластик әйберләр алыштырды, җиләк-җимешне пластмасса чиләккә җыю гадәткә керде.

Ата-баба һөнәре онытылып барган, табигый материалдан ясалган көнкүреш әйберләре кулланылыштан чыккан заманда болыт астыннан ялтырап чыккан кояш сыман һөнәрмәндләрнең кул эшләре янә тормышыбызга әйләнеп кайта башлады.

Һөнәрмәндләр дип күплек санда әйтүен әйттем дә, уйга калдым, ни кызганыч, берән-сәрән генә очрый шул алар.

Новотроицкое авыл җирлегенә керүче Шөкрәле авылында әнә шундый бик борынгы һәм кирәкле һөнәр иясе гомер итә.

Уңган-булган пар

Рәсимә Хәмәт кызы белән Юсуп Алланияз углы Бикниязовлар яры гасырга якын матур пар булып гомер итәләр. Рәсимә ханым – шушы яктан, шушы туфрактан – Шөкрәлесенә гомере буе тугры калган ханым. Ул гомере буе почта бүлекчәсе башлыгы булып хезмәт куйган.

– Пенсиягә чыккач та бер ел эшләдем. Халык ябырылып газета-журнал укый иде элек, һәр гаилә «Якты юл»ны яздырып алдырды. Кимендә алты-җиде исемдә газета-журнал килә иде һәр йортка. Бәйрәм алдыннан хат, открытканы пачка-пачка тарата идек. Пенсия акчасын халыкка тапшыру да безнең вазыйфага керде ул чорда. Яратып башкардым эшемне. Хуҗалыгыбызда мал-туарны күпләп асрадык. Тавык-кошның исәбе-чуты булмады. Ике ир бала да шул арада үсеп җиткән. Ул чорларда бар эшне кул көче белән башкара идек. Шулай да, ничектер авыр итеп кабул итмәдек тормышны. Аллаһка шөкер, хәзер тормыш итү җиңелләште. Йортта, каралты-кура тирәсендә механика-автоматика дигәндәй, барысы да бар. Бөтен теләк – ил-көннәр тыныч булсын, – ди Рәсимә апа.

Аның сүзенә ире – Юсуп абый кушыла: «Армиядә хезмәт итү бик абруйлы иде безнең чорда. 1973 елда армия хезмәтен тәмамлап шушында – әнинең туган авылына кунакка кайттым һәм гомерлеккә төпләнеп калдым. «Новотроицкое» совхозына механизатор булып эшкә урнаштым», – дип сөйли тумышы белән Каракалпакстан якларыннан булган Юсуп ага.

Эш дип кулы «кычытып» тора

Эш сөйгән, тиктормас холыклы кеше турында безнең халык: «Ут борчасы сыман, кулы эшкә кычытып тора» дигән сыйфатлама куллана. Юсуп ага гомер буе эш дип «кычытып торган» кулына лаеклы ялга чыккач эш тапкан – борынгы һөнәрне үзләштергән – тал чыбыгыннан төрледән-төрле әйберләр үрә, кухня кирәк-ярагы ясый.

– Табигый материаллардан, бинаның эчен ут белән бизәп, мәчет макетлары ясадым. Үзебезгә дип калдырганын да сатып алдылар. Ясаган әйберләремне халык бер-берсеннән күрә, кызыксына һәм килеп ала. Песи ояларына аеруча сорау зур. Мәче халкы, күрәсең, талчыбыктан ясалган өйне хуп күрә. Ярминкәләрдә, төрле мәдәни чараларда үткәрелә торган күргәзмәләрдә кәрҗин, тырыс, җиләк-җимеш салу өчен вазалар, ипи-сохари савытлары тирәсендә хатын-кыз мәш килә – сыпырып алып бетерәләр. Заказ буенча да эшлим. Чаллыда зур гына Мәдәният сараенда бүлмә-мастерской биреп, эшемне киң җәелдерергә тәкъдим ясаганнар иде. Яшьрәк чагым булса уйлап караган булыр идем әле. Хәзер олыгайган чорда үз көемә эшләүне хуп күрәм. Аннары, илһамланып эшләргә яратам мин, үз җаема гына, – ди һөнәр иясе.

– Юсуп бөтен эшне күңел биреп башкара, менә бу үрү эшен дә җеген җеккә китереп эшли. Бу әйберләрне ясау өчен түземлелек бик кирәк. Бәләкәй бүлмәсендә – остаханәсендә көннәр буе эшләп утыра. Ике улыбыз да әтиләре сыман – нәрсәгә тотынсалар да, булгач булсын, берәгәйле булсын, дип эшлиләр. Бала ата-анасында булган гадәтләрне күреп үсә, аларга охшарга тырыша. Эшне ихласлык белән башкару шул кечкенәдән аңнарына сеңә, күрәсең, – ди Рәсимә ханым, ире һәм уллары белән горурланып.

Рөстәм Зәкиев

Ел әйләнәсе эшләү өчен материал кул астында – без яшәгән тарафларда талга иркенләп үсәргә шартлар җитәрлек, ул шуңа да киң таралган. Су буйларының гомерлек юлдашы булган «сагышлы тал» ботаклары – эш өчен аеруча кулай сортлардан. Ул халыкта елаучы тал – «плакучая ива» дип атала. Юсуп ага тал чыбыгының кәефен чамалап, эшкә яраклысын белеп кенә җыеп алып кайта. Тиешенчә эшкәртә һәм талчыбык – син күр дә мин күр! – мамык, йон җебедәй «тыңлаучан»га әйләнә.

– Талчыбыкның кайрысын суергач, зур алюмин кәстрүлдә ике-өч сәгать кайнатам. Технологиясен белеп, төгәл үтәсәң, көйле генә эш материалы килеп чыга. Теләсәгез, сез дә өйрәнә аласыз бу эшкә. Бары тик теләк һәм кызыксынучанлык кирәк. Нигәдер яшьләр бу эшкә күңел бирми. Күрәсең, аларны телефон үз эченә «йоткан». Шунысы да бар: интернетны дөрес итеп файдаланырга – тормышта куллана белергә кирәк. Бу һөнәрнең серенә интернет аша төшендем, төрле әйберләр ясарга өйрәндем. Хәзер дә белемемне, осталыгымны шушы замана чарасы аша арттырам. Аннан соң, һөнәрченең эшендә үзе генә белгән сере була. Кайбер әйберләрне бизәп эшләргә яратам. Ясалма, синтетик әйбер кулланмыйм, төсләр белән бизәкләгәндә аш-су буявы кулланам. Шоколад, какао төсе затлы төсләрдән санала. Аның өчен дә табигый буяу кулланам, – ди мастер.

«Хатын-кыз бәйләм бәйләп, чигү чигеп, кул эше белән юана. Сәламәтлек өчен файдасы бар, диләр. Табигый материал белән эшләү бармакларга яхшы тәэсир итәдер», – дим.

– Бармак очларында нерв җепселләре тупланган. Шуларны «эшләтү» сәламәтлеккә уңай тәэсир итә. Тынычландыра. Агачның хуш исе ни тора! Күңел теләгәнчә эшләгәч, кәеф күтәрелә. Аннары, яшерен-батырын түгел, азмы-күпме сәмәне дә керә. Ни әйтсәң дә, эшләнмәләрне ясау өчен кайбер әйберләрне сатып алырга туры килә, – дип үз һөнәренең файдалы яклары турында искәртә Юсуп ага.

«Талбишек ясаячакмын! Интернеттан өйрәндем, эшли башладым инде». Юсуп ага шулай ди.

Зәрия ВӘЛИЕВА.
Тукай районы

Шөкер итәрлек

Халыкка комплексы хезмәт күрсәтү үзәкләре социаль өлкәгә кагылышлы бурычларны хәл итүдә зур роль уйный. Сабада урнашкан «Балкыш» халыкка комплекслы хезмәт күрсәтү үзәге республикада алдынгы урында тора. Аның эшчәнлеге турында үзәк директоры **Гүзәл ЗАКИРОВА** белән сөйләштек.

:: Сезнең үзәктә өлкәннәргә игътибар зурмы?

– «Демография» милли проекты кысасында 2021 елда халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге базасында 18 яшьтән 40 яшькә кадәрге, аутистик тайпылышлары булган инвалидлар өчен көндезге төркем оештырылган иде. 2022 елда менталь тайпылышлары булган 20 инвалидка педагогик һәм психологик ярдәм күрсәтелде. Халыкка комплексы хезмәт күрсәтү үзәгенең икенче тармагы – өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсе (җитәкчесе – Алсу Степанова). Бүлекчәнең төп максаты – өлкән яшьтәге һәм ялгыз яшәүче мөмкинлекләре чикле кешеләргә социаль, медицина хезмәте күрсәтү. 2022 елда барлыгы 232 кеше ярдәм алды. Ел дәвамында 71 мохтаҗ кеше ачыкланып, исәпкә куелды.

:: Алар социаль хезмәткәрләрдән канәгатьме?

– Бүлекчәдә 36 социаль хезмәткәр 195 өлкән кешене кайгырта. Эшләреннән ризасызлык белдерүчеләр юк.

:: «Демография» милли проектына бәйле чаралар белән дә таныштырыгыз әле.

– 2019 елдан әлеге проект кысасында Татарстанда өлкән яшьтәгеләрне һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбияләү системасын гамәлгә кертү башланды. Төбәк проекты республикада «Өлкән буын» исемен алды. Проектны гамәлгә ашыру кысасында 2022 елда Саба үзәк хастаханәсе медицина хезмәткәрләре белән берлектә 119 өлкән яшьтәге кешегә һәм инвалидка комплексы социаль хезмәт күрсәтелде. Ел саен торак-көнкүреш шартларын, газ, электр үткәргечләрен тикшерү һәм социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлыкларын ачыклау максатыннан ялгыз яшәүче өлкәннәрнең өйләренә йөреп чыгу оештырыла. 2022 елда шул максаттан 80 яшьтән узган 519 кеше тикшерелде. Аның нәтиҗәләре буенча 39 ялгыз яшәүче кешегә социаль хезмәткәр беркетелде, 3 елда «сиделка» ярдәме алучылар 17гә җитте.

2019 елда «Демография» милли проектының «Өлкән буын» проекты кысасында үзәккә «LADA Largus» автомобиле кайткан иде. Ул 65 яшьтән узган өлкәннәрне һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне медицина учреждениеләренә алып бару өчен каралган. 2022 елда авыл җирлекләрендә яшәүче 1470 өлкән кеше поликлиникага китерелде. Бу – планга караганда 45 кешегә күбрәк.

Фәнил МӘҮЛЕТОВ.
Саба районы

ЭРЕТҮЧЕ МӘРЗИЯ

Хезмәтем буенча нинди генә һөнәр ияләре белән аралашырга туры килмәде. Әмма шулар арасыннан эретеп ябыштыручы булып эшләгән хатын-кыз белән очрашу гомергә күңелемдә калды. Мәрзия апага карап сокландым мин.

Саба районының Урта Саба авылында туып-үскән Мәрзия апа яшьтән эш сөйгән, эш яраткан. Мәрзия апа әтисенең сугыштан кайткан көнен яхшы хәтерли. Бу чакта аңа 8–9 яшьләр чамасы була. Сөенчене исә ул көнне дәрескә килмәгән сабакташы Фәния ала. «Мәрзия, бар йөгер, әтиең кайтты!» – дип оран сала ул бар җиһанга. Укытучы Камилә апасы шундук аңа өенә кайтырга рөхсәт бирә. Ләкин Украина, Белоруссия фронтларында сугышкан, күпсанлы медальләргә лаек булган һәм нык яраланган Зиннәтулла агайга озын гомер кичерергә насыйп булмый. Гомеренең соңгы елларын күмәк хуҗалыкта атлы эштә эшләп үткәргән Зиннәтулла ага сугышта алган яралардан мантый алмыйча, 1966 елда вафат була. Авыл фермасында хезмәт куйган әнисе Хөббениса апа озын гомерле була. Ул Урта Саба авылында төпчек улы Мәгъсүм, килене Нурия тәрбиясендә озын һәм бәхетле картлык кичереп дөнья куя.

Мәрзия апа һәрвакыт һөнәр алырга омтылган. Белемгә омтылу аны алты айлык эретеп ябыштыручылар курсына алып килә дә инде. Укып бетергәч, аларны хром заводына эшкә җибәрәләр. 25 ел эретеп ябыштыручы булып эшли Мәрзия апа. Лаеклы ялга чыккач та кул кушырып утырмый, эшләвен дәвам итә, «Горпищеторг» дигән оешмада эретеп ябыштыручы буларак хезмәт куя. Биредә дә сынатмый, эшен намус белән башкара. Тиз арада коллективның хөрмәтен яулый, үз адресына мактау сүзләре ишетә, бәйрәмнәрдә бүләкләр, Мактау кәгазьләре ала, ул чакта «иң-иң»нәргә генә бирелә торган «Социалистик хезмәт ударнигы» дигән мактаулы исемгә лаек була.

1969 елда Чүлпыч авылы егете Габдрәшиткә кияүгә чыккач, алар Уралда төпләнәләр. Шушында 50 ел гомер сизелми дә узып китә. Бергәләп ике егет, бер кыз үстерәләр.

Әмма ничә еллар узгач, туган җирнең тарту көче барыбер үзенекен итә. Алар 2009 елда Теләчегә терәлеп утырган Комаровка авылында өй сатып алып, шунда кайтып төпләнәләр. Дөрес, Габдрәшит агага туган як һавасын озак суларга туры килми, 2019 елда дөнья куя. Мәрзия апаны балалары ялгыз итмиләр. Әле берсе, әле икенчесе, оныклары кайтып тора.

Мәрзия апа, Комаровкадагы күршеләремнән бик уңдым, ди. Гел ярдәм итәргә генә торалар икән. Үзе исә аларны кайтып төпләнгәч, яшелчә, җиләк-җимеш бакчасында башкарган эретеп ябыштыру эшләре белән шаккатырган. Шулай булмый ни – алтынчы разрядка ия эретеп ябыштыручы Мәрзия бит ул.

– Габдрәшит абыең да әйбәт булды. Бар эшләгәнен өйгә алып кайта иде, башкалар кебек исраф итеп, аракы эчеп йөрмәде. Дус-тату булып, бер-беребезне нык хөрмәт итеп яшәдек. Какмады-сукмады, бик бәхетле гомер кичердек, – ди Мәрзия апа. – Кеше беркайчан да эшләп үлми. Бәлкем, озын гомерле булуымның дә сере шундадыр.

Фәнил НИГЪМӘТҖАНОВ.
Теләче районы

ВЛАДИМИР КУЗНЕЦОВ:

ШАТЛЫГЫ ДА, КАЙГЫСЫ ДА УРТАК БУЛДЫ

Авыл кешесенең хезмәте элек-электән хөрмәтләнгән. Ял һәм бәйрәмнәрсез иртә таңнан кичкә кадәр хезмәттә бит алар. Гомерен авыл хуҗалыгында эшләүгә багышлаган, Чүпрәле районының Матак авылында яшәүче Владимир Кузнецов та бик күпләргә үрнәк.

Кузнецовларның гаиләсе күпбалалы.

– Әтием Бөек Ватан сугышында катнашкан. 1943 елда фронтка киткән һәм 1950 елда гына әйләнеп кайткан. Сугыштан соң әти Киров өлкәсенә яхшы тормыш эзләп киткән җиреннән бик нык авырый башлый. Аны күпмедер дәрәҗәдә дәвалап, туган якларга алып кайтырга дип, артыннан әни юлга кузгала. Бу вакытта гаиләдә инде алты бала үсеп килә, иң олысы – мин. Без шулай итеп әби тәрбиясендә калдык, – дип сүзен башлады юбиляр. – Бераздан әни белән әти кайтты. Тормыш җайланып та китте кебек, әмма миңа, олы бала буларак, югары белем алу насыйп булмады. Армия хезмәтеннән соң шофер белемем белән колхозда эшкә калдым. Әти-әнигә дә ярдәм кирәк иде, кече туганнарымны тәрбияләү дә минем өстә булды.

Владимир Поликарповичның хезмәт биографиясе авыл хуҗалыгы тармагына тыгыз бәйләнгән. Гади шофердан башланган хезмәт юлы аны дәрәҗәле вазыйфаларга кадәр җиткерә.

«Авангард» колхозында машина йөртүчедән соң аны кыр бригадиры итеп билгелиләр, анда ул үзен принципиаль эшлекле белгеч итеп күрсәтә. «Эшләргә теләк бик зур иде. Ул чорда коллективта барыбыз да – татарлар да, чуашлар да намус белән, булсын дип эшләдек, – ди әңгәмәдәшебез. – Тәүлегенә 12 сәгать, хәтта күбрәк тә хезмәт иттек. Өйгә йокларга гына кайтылды. Мин киткәндә дә, эштән соң кайтканда да өйдә балалар йоклый иде инде».

Район җитәкчелеге, яшь белгечнең оештыру сәләтен исәпкә алып, Матак филиалының «Ак Барс – Чүпрәле агрофирмасы» җәмгыятенә ферма мөдире итеп билгели. Ул кыска вакыт эчендә бердәм эшче коллектив төзи һәм аларны югары җитештерү күрсәткечләренә ирешүгә юнәлтә ала. Лаеклы ялга чыкканчы, шунда хезмәт куя Владимир әфәнде.

Ветеранны бүгенге авыл тормышы борчый.

– Элек халык эшләде дә, ял да итә белде, шатлыгы да, кайгысы да уртак булды. Бүген авыл урамнары буш, моңсу, җирдә эшләргә теләүчеләр бик аз, – ди ул.

Владимир Кузнецов – кызыксынучан, күпкырлы кеше. Күңеле тулганда, кулларына гармун алып, төрле халык көйләрен суза. Кышын чаңгысын киеп, урман буйларын әйләнеп кайта, аларның йортлары да урманга терәлеп диярлек урнашкан. Җәйләрен шунда мунча себеркесе, дару үләннәре, җиләген, гөмбәсен җыеп уза.

Хуҗалыгында җан дуслары – әллә нинди төсле куяннары да байтак. Алар гадәти түгел, «француз» токымлы. Саннары да йөзгә җиткән. Үзенең умартачылыгы да бар.

– Ялгызлык кына авыр. Көндезләрен вакыт уза, ә менә кичкә кергәч, телевизор да карыйм, радио да тыңлыйм, шулай да вакыт узмый, – дип, карчыгын юксына ул.

Хатыны Валентина белән 45 елга якын тату гомер итә алар. Әмма 2 ел элек ялгыз кала ул. Алар биш бала тәрбияләп үстергәннәр. Кызлары медицина белемәнә ия, берсе авылда ФАПта эшли. Ике улы – хәрби хезмәткәр.

Сүз уңаеннан, Кузнецовлар гаиләсендә хәрби юнәлеш буыннан-буынга бара. Владимир Поликарпович сүзләренчә, әтисенең энесе хәрби кеше булган, шулай ук аның үз туганнары арасында да хәрбиләр бар.

Ветеран хәзерге көндә дә авылның иҗтимагый тормышында актив катнаша, Матак һәм Чуваш Ишлесе авылларында ветераннар советы рәисе вазыйфасын башкара.

Гөлия ФӘИЗОВА.
Чүпрәле районы

Тулы бәхет

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тырыш һәм намуслы хезмәтләре өчен бүләккә бирелгән туристик юллама белән Польша һәм Чехословакиягә барулармы, Кырынды мәчетенә яки төрле җирләрдәге туганнары, дусларына юл тоталармы – алар гел бергә. Алтмыш ел бергә тату, аңлашып, матур яшәгәч, бай тәҗрибә белән уртаклашсаң да була. «Матур яшәүнең нигезе өлкәннәрдән башлана, – дип сөйли Рәисә апа. – Каенатам Хикмәтулла, каенанам Мәгъсүмә мине үз кызлары кебек кабул иттеләр. Балаларыбызны үстерергә булыштылар. Шунысын да әйтергә кирәк: Мөбин дөнья йөген үзе күтәреп барды. Мин бер әйбер өчен дә кайгырмадым. Барысы өчен ул йөгерде. Миңа шундый яхшы ир үстергән ата-анага ничек хөрмәт күрсәтмисең?!»

Мөбин абый белән яшәеш, тормыш турында сөйләшә башлагач, ул да сүзен әти-әнисеннән башлады. «Әтием Хикмәтулла муллалыкка укыган иде. Ул сугышка киткәндә, без биш бала калдык, кечкенәбезгә бер ай гына. Әни кичләрен безгә догалар өйрәтә иде. Аллаһы Тәгаләдән әтиебезнең исән кайтуын сорадык. Иншаллаһ, исән-сау әйләнеп кайтты. Әтием 20 ел мулла, әнием абыстай булды. Аллага шөкер, Рәисәм – ышанычлы тормыш юлдашым. Аны хәзер дә бик яратып яшим», – ди Мөбин ага. Рәисә апа һәм Мөбин абыйларның матур, тату гаиләсенең нигезен тәшкил итүче ярату хисе, өлкәннәрнең бәхиллеге, гүя башка кидерелгән гүзәл таҗ, муенга тагылган нәфис мәрҗән-бизәк булып яшәешләрен якты, нурлы итә.

Олыны олы итә белгән тәртипле гаиләдә өч кыз үскән. Резидәләре – Балтачта, Гөлзидә белән Минеһөдәләре Ижау каласында яшиләр. Бәхетле әби-бабай сигез оныгының, унбер оныкчыгының да уңышларына сөенеп, аларның үзләре кебек эш сөючән, тырыш һәм итагатьле булып үсүләренә сөенеп гомер кичерәләр.

Кәримуллиннарның заманча тышланган иркен йортлары, нур сибеп торучы тәрәзә йөзлекләре, төзек каралты-куралары, бакчада тезелеп киткән умарталар бирелдә уңган-булган хуҗалар яшәвен күрсәтеп тора. Әнә шулай, үз тырышлыклары белән төзегән дөньяларында хезмәттән тәм, тормыштан ямь табып, кешеләргә ярдәм итә алуларына куанып, Кырындыда ике мәчетнең дә гөрләп эшләвенә шатланып, Аллаһ юлында йөрүләренә сөенеп, бәхетле яши алар. Гаилә учагыгыз һәрвакыт бәхет белән мөлдерәмә тулып торсын. Бриллиант туегыз мөбарәк булсын!

Асия КОРБАНГАЛИЕВА.
Әгерҗе районы

МИЛЛӘТ АНАЛАРЫ

Казаныбызның «Рауза мәчете» мәхәлләсе «Милләт аналары» дип исемләнгән очрашулар циклын башлап җибәрде. Мәчет үткән елның сентябрь аенда ачылган иде һәм беренче көннәрдән үк Сеченов урамындагы гыйбадәтханә өлкәннәрне дә, яшьләрне, зыялы, абруйлы шәхесләребезне, дин әһелләрен дә үзенә җәлеп итте. Намаз уку өчен дә, очрашулар өчен дә биредә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. «Милләт аналары» очрашулары яшьләрдә өлкәннәргә карата миһербанлык тәрбияләүне, тарихыбызны барлауны һ.б. максат итә.

Беренче очрашуга танылган дин әһеле Габделхак хәзрәтнең кызы Фирдәвес ханым Саматова һәм Габделхак хәзрәтнең оныгы Камил хәзрәт чакырылды. Очрашуга «Рауза мәчете»нең имамы Илнур хәзрәт Вафин, Илшат хәзрәт Насыйбуллин, Илдар хәзрәт Вәлиуллов, Рөстәм хәзрәт Бикитеев, остазлар, шәкертләр килгән иде.

Татар мөселман дөньясының легендасы – галим, имам-хатыйп, казый, ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсен оештыручы Габделхак хәзрәт Саматов дини гыйлемне кайларда, кемнәрдән алган? Ислам диненә мәхәббәт орлыкларын аңа кем салган? Әлбәттә, иң әүвәле шушы сорауларга ачыклык кертелде.

1990 елда Габделхак хәзрәт Чистай шәһәрендә мәдрәсәгә нигез сала. Шунда бер ел белем биргәч, башкалабызның да мәдрәсәле булуын теләп, үзенең шәкертләре белән Казанга күченә һәм Габделхак хәзрәт тырышлыгы белән Казан арты мәчетендә мәдрәсә ачыла, 1998 елда ул Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые вазыйфасында да була.

Фирдәвес апа хәтер-хатирәләреннән:

– Заманында әти бер оешмада шофер булып та эшләде. Яңа ел алдыннан җитәкчелек аңа кибеттән исерткеч эчемлекләр алып кайтырга куша. Шунда әти аптырап кала һәм: «Юк, мин йөртә торган машинага аракылы шешәләр төямибез һәм төямәячәкбез дә», – ди. Аның җаваплары менә шулай һәрвакыт төгәл һәм аңлаешлы иде. Берәү булса, җитәкче кушканны үтәмәсәм, эштән куулары да бар бит, дип уйларга да мөмкин. Әти фикереннән күчми торган кеше иде.

Кемнең кем булуына карамастан, елмаеп каршы ала торган, елмаеп озата торган кеше иде әтиебез. Казанда, төрле милләт вәкилләре белән аралашып яшәсәк тә, үзара бары тик татарча гына аралаштык. Вакыт-вакыт русча сүз башласак, әти дә, әни дә ишетмәмешкә салышалар, җавап кайтармыйлар иде.

Әти белән әни тумышлары белән Аксубай төбәгеннән. Әти гаиләдә тугызынчы бала булып дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа унбер яшь була. Колхозга тискәре мөнәсәбәттә булганы өчен бабайны ирегеннән мәхрүм иткән булалар. Әти туган төбәгендә дә күрше районнар дин әһелләреннән дәресләр алган була. 15 яшендә инде ул рәхәтләнеп Коръән укый, дини мәҗлесләрдә бик еш чыгыш ясый. Аңа: «Син дини белемне киләчәк буынга илтүче элемтәче булырсың», – диләр. Шулай була да.

Әти мине бик яратты, мин дә аны өзелеп яраттым. Барлык туганнар да әтигә дин сабагына йөри иде. Без кимендә өч яшьтә намазда идек инде. Аны шәкертләре дә бик сагынып искә ала.

«Инде ничә еллар узды, күпме сулар акты, тормыш юллары үтелде, ә рухи остазым инде күптән ахирәт әһеле булса да, аның хикмәтле фикерләре, киңәшләре онытылмый – күңелемне яктыртып, җылытып, өметләндереп, киләчәккә ныклы ышаныч баглап яшәргә һаман ярдәм итә. Ничектер бер уйлап куйдым: намазда имамга ою бар, шулай ук имамны үзеңнең остазың, киңәшчең, терәк-таянычың итеп тоеп, аңа рухи мәгънәдә гомер-гомергә ою да бар. Габделхак хәзрәт белән танышып, аның белән аралаша башлаганнан соң, мин дә ошбу имамга оедым – аны үзем өчен гомерлеккә остаз итеп сайладым. Аңа Аллаһның рәхмәте булсын, аның белән бергә Аллаһ җәннәтендә очрашырга насыйп әйләсен». Искиткеч тирән бу сүзләрне Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат хәзрәт Курамшин әйтә. Башка шәкертләре дә нәкъ менә шушы фикердә.

Очрашуга нәтиҗә ясап, имам Илнур хәзрәт Вафин болай диде: «Рауза мәчете»ндәге төп юнәлешләрнең берсе – телне, динне хөрмәт иткән эшчән-булган нәсел дәвамчылары тәрбияләү, әтиәниләрнең дәрәҗәсен күтәрү, милләтебезгә хезмәт итү. Бу адымда безгә өлкәннәрнең булышлыгы бик тә кирәк. Очрашуларыбыз дәвамлы, нәтиҗәле булсын! Бергәлек, бердәмлек булганда бернинди дә киртә була алмый».

Шулай, Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга җан тынычлыгы, тәнгә сәламәтлек, озын гомер әйләсен!

Чулпан МӘХМҮТОВА,
укыту-тәрбия эшләре буенча
имам ярдәмчесе



ЯШЬЛӘРГӘ ҮРНӘК

Полиатлон буенча өч тапкыр дөнья чемпионы, ун тапкыр Россия чемпионы, республика күләмендә узган күп кенә ярышларда җиңүче 84 яшьлек Мәннаф Хөҗҗәтов әле дә мәктәп укучыларына физик тәрбия бирә.

– Мин 80 яшемдә укытудан туктадым. Алай да мәктәптән аерылдым дип әйтеп булмый әле. Аратирә барып укучыларга мастер-класс үткәрәм. Кызганыч, күпчелек балалар физик яктан көчсез. 15 малайның бер-икесе генә турникта күтәрелә ала. Турникта тартылу телефон сыпырып утыру түгел шул, – ди Мәннаф абый. – Ә бит егетләргә хәрби әзерлек бик кирәк. Әле менә үз районыбызда спорт ярышы уздырырга дип торабыз. Укучыларны өч төрле спорт төрендә сынаячакбыз. Беренчесе – турникта тартылу, икенчесе – чаңгыда шуу, өченчесе – ерактан ату.

Мәннаф абый үзен егетләрчә хис итә. Әйтик, турникта 40 мәртәбә күтәрелә. Йөгерергә дә оста. Кыскасы, сәламәт яшәү рәвеше алып бара. Элек көрәш мәйданына да чыккан. Күп мәртәбәләр Сабантуй батыры да булып калган. Күпләр аның ничек туклануы белән кызыксына, без дә сораштык. «Кечкенәдән йөгергәч, ашказаным зур түгел. Әмма көнгә әз-әзләп 4–5 тапкыр ашыйм. 67 килограмм авырлыгымны тотам», – ди ул.

Спорт белән дус булгач, коронавирус белән дә каты авырмаган. Бу чирне шулай җиңел уздыруын дөрес яшәвеннән күрә.

– Мин үземә бик таләпчән. Иртәнге алтынчы яртыда йокыдан торам да физзарядка ясыйм. Башта мускулларны җылытам, җиңелчә генә күнегүләр ясыйм, гантельләр күтәрәм, турникта тартылам. Кышын көненә ике тапкыр чаңгыда йөрим, атнасына бер тапкыр булса да, йөзәргә тырышам, – ди ул.

Балаларга да шуны өйрәтәсе килә аның. Мәктәптә укыткан елларындагы егетләр, армиядән кайткач, рәхмәт әйткән үзенә. «Чын ир-ат итеп тәрбияләдегез», – диләр икән. Мәннаф абыйның тәрбиягә эче поша да инде. Малайларны дөрес үстермибез, ди ул.

– Тәрбия бирү хатын-кыз өстенә өелеп калды. Ә бит егет кешене ир-ат тәрбияләргә тиеш. Әни белән үскән бала әллә кайдан күренеп тора. Гәүдәсенә бер карау җитә, – ди ул. – Бар теләгем – балаларны спортка тарту. Спортны яраткан бала югалмый, сәламәт була, авырлыкларны да җиңә ала!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Бергә булганда, җиңелмәс көч без

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Өлкәннәр еш кына, ярдәм фронтка килеп җитәме икән, дип сорый. Моңа бернинди дә шик юк. Без хәрбиләргә тәгаенләнгән посылкаларны алгы сызыкка китерүче волонтерлар белән элемтәне җайга салып, аларга нәрсәләр кирәклеген бик яхшы беләбез, – диде Гүзәл ханым. – Туклануга бәйле кыенлыклар юк инде хәзер. Шул ук вакытта көндәлек кирәкле әйберләргә – оекбаш, резин итек, эчке кием, дымлы салфеткаларга ихтыяҗ зур. Шулай ук юынуга бәйле проблеманың барлыгын аңладык. Волжск шәһәреннән «Нить добра» хәйрия оешмасының фронтка мобиль мунчалар озатуын ачыкладык».

Менә хәзер Казан активистлары бу эшкә кушылмакчы. Тиздән Татарстанның «Алга» батальоны махсус хәрби операция зонасына китәчәк. Аксакаллар шулар белән алгы сызыкка, солдатларның соравы буенча җыелган йөк белән бергә, машина арбасына тагып, мобиль мунча да алып киләчәк.

Әгерже районы ветераннары советы рәисе Эльвира Нәбиева җирле аксакалларның хәрбиләребез өчен башта чәй, бал кебек азык-төлек җыюлары турында сөйләде. Шуннан соң алар җылы кием-салым җыюга күчкән. Әгерҗедә тимерьюлчылар күп яшәгәнлектән, кешеләр капчык-капчык шушы һөнәр ияләренең махсус кием-салымын – комбинезон, бушлатлар ташыган. «Бигрәк тә Кичке Таң авылы ветераннарының башлангыч оешмасы бик әйбәт эшли, – дип билгеләп үтте чыгыш ясаучы. – Бу авыл җирлегеннән махсус хәрби операция зонасына 6 ир-егет киткән. Активистларыбыз аларның гаиләләрен кайгыртуны үз өстенә алды. Уларын озатып, ярдәмчесез калучыларга аеруча зур игътибар бирелә». Мәсәлән, бер солдатның инвалид әнисенә ярдәм ителгән. Ветераннар, акча җыеп, аңа дарулар, кан басымын үлчәү приборы сатып алган, утын юнәтергә булышкан. Башка җирлекләрдә фронт өчен кул токмачы, окоп шәмнәре ясыйлар, яшьләрне шушы эшкә өйрәтәләр.

«Бүген бездә бу хәйрия эшенең урыннарда ничек алып барылуын белешү ниятеннән тәүгә «перекличка» уздык. Хәзер без аны һәр атна саен үткәрәчәкбез. Мондый чарада һәрбер район ветераннары үзләренең эше турында иркенләп сөйли алачак», – дип йомгак ясады Хәбир Иштирәков.

БЕРЕНЧЕ БУЛДЫМ

Моннан 36 ел элек, 1986 елның 17 декабрендә СССРда беренче Ветераннар советы төзелде (1991 елның 27 ноябрендә ул «Россия Ветераннар советы» дип үзгәртелде). ТАССРда беренче Ветераннар советы төзелүгә 2023 елның май аенда 36 ел тула. Ә безнең Иске Абдул авылында беренче ветераннар оешмасы моннан 54 ел элек – 1968 елның 9 маенда төзелде. Һәм мин 36 ел дәвамында авылыбызда Ветераннар советы рәисе булдым.

Шулай итеп, мин СССРда һәм ТАССРда – беренче Ветераннар советын төзүче, аның беренче рәисе һәм иң озак шул вазыйфада эшләүче кеше булдым. Моның белән бик горурланам.

Беренче Ветераннар советы төзелүнең тарихы болай: 1960 нчы елларда республика мәктәпләре ТАССР мәгариф министры академик Мәхмүтовның «Проблемалы укыту» дигән алымы белән эшләде. Һәр мәктәп, һәр укытучы ниндидер бер проблеманы хәл итү юнәлешендә иҗади эш алып барырга тиеш иде. Безнең мәктәп 1962 елдан «Укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирү» юнәлешен сайлады. Республикада беренче мәктәп музеен ачтык, «Аҗаган» уенын оештырдык, Җиңү һәйкәлен төзедек; хәрби парад үткәреп, 1964 елда СССР күләмендә «Җиңү көне»н кайтардык (ә ил күләмендә 1965 елда кайтарылды, 20 еллыкка) һ.б.

Ә 1968 елның 9 маенда, минем инициатива белән, укучыларны сугышчыларның батырлыгы үрнәгендә тәрбияләү максатында, авыл Ветераннар советы төзелде (авыл советы буенча 92 сугыш ветераны исән иде). Совет рәисе итеп мине сайладылар. СССРда һәм ТАССРда Ветераннар советы төзелгәнче, мин 16 ел дәвамында Ветераннар советы рәисе булдым.

1984 елда безнең авылны Минзәлә районыннан Тукай районына куштылар. Илкүләм Ветераннар советы төзелгәч, аның рәисе сугыш ветераны булырга тиеш дип аңлаттылар. 1988 елда авыл Ветераннар советы рәисе итеп Миннеәхмәт абый Диниев сайланды.

1997 елда мине тагын Ветераннар советы рәисе итеп сайладылар. 2017 елга кадәр, 84 яшем тулганчы тагын 20 ел дәвамында эшләдем. Бу чорда инде барлык пенсионерларны да кертеп, советта 205 кеше бар иде. Әнә шулай итеп 36 ел Ветераннар советы рәисе булдым.

Шул чорда күп кенә мөһим эшләр эшләнде. 50 елга якын республика күләмендә патриотик тәрбия эшен әйдәп баручыларның берсе булдым. Ә хәзер, соңгы 15 елда укучыларым – Әфган сугышы ветераннары патриотик тәрбия эшен республика күләмендә әйдәп баралар. Әфган сугышында катнашкан 10 укучыбыз да исән-сау кайттылар. 2009 елда Айбулат Якупов җитәкчелегендә «Гиндукуш» хәрби дан музее ачтылар. Ул музей республиканың барлык әфганчыларын берләштерде.

Аннан, район буенча Әфган сугышында һәлак булучылар бар. Тик бер җитәкче дә һәйкәл төзүгә алынмый. Тагын Айбулат Якупов җитәкчелегендә авылыбыз әфганчылары үз инициативалары һәм көчләре белән һәйкәл төзеделәр.

Колхозыбызны («Алга» колхозы) агрофирма составына кушып тарата башлагач, Ветераннар советы рәисе буларак, 205 пенсионер-ветеран исеменнән район прокуроры ишек бусагасын таптап, кушуның нигезсезлеген дәлилләп судка биреп, колхозыбызны банкрот итмичә, агрофирмадан аерып чыгарып, аны саклап калдым. Бу – соңгы 20 елда Ветераннар советы рәисе булып эшләү чорында иң зур хезмәтләремнең берсе.

Җир пайларын рәсмиләштергәндә дә, «ышанычлы зат» дигән төшенчә юк чорда ук, Ветераннар советы исеменнән җир пайларын рәсмиләштерү артыннан йөри башладым һәм инвесторларга җиребезгә хуҗа булырга ирек куймыйча (закон чыккач, мине «ышанычлы зат» итеп сайладылар), республикада – беренче унлыкта, ә районда беренче булып җир пайларын рәсмиләштердем. Бүген барлык җир пайларыбыз да үзебезнең колхозда. Колхозыбыз нык. Көн саен 20 тонна (әйе, егерме тонна!) югары сыйфатлы сөт, сортлы орлыклар сата. Халыкка эш бар. Игенчелектә дә, терлекчелектә дә югары технологияләр кулланалар. Өлкәннәргә дә ярдәм зур, инде 19 ел дәвамында сугыш чоры ятимнәренә бүләк бирелә. 17 ел дәвамында 80 яше тулучыларның бәйрәмен үткәрәбез, анда да колхоз һәрберсенә бүләк итеп 5әр центнер ашлык бирә. Быелга кадәр пай җирләренә иң күп түләү республика күләмендә безнең «Сайдәш» колхозында булды (быел – 3 нче урында). 2017–2021 елларда Ветераннар советы рәисе Клара Хөсәенова булды, бүген – Лена Вахитова, ул да әйбәт эшли. Син башлаган эшне дәвам итүчеләр яхшы эшлиләр икән, бу – сиңа да шатлык. Димәк, традиция дәвам итә.

Авылыбыз төзек. Авылыбызда 4 һәйкәл, 2 музей бар. Һәйкәлләрнең икесен мин төзеттем, музейның берсен мин ачтым. Авылыбыз тарихы турында 4 китап яздым. Безнең авыл колхозлы да, тарихлы да, музейлы да, һәйкәлле дә. Бик күп чаралар үткәрелә һәм ул чәй өстәле янында дәвам итә. Шунда еш кына, колхоз җитәкчеләренә рәхмәт әйткәндә: «Сугышлар гына чыкмасын да колхоз гына таралмасын», – диләр. Колхоз таралуны сугыш чыгу белән тиңлиләр икән, димәк, колхозның нәрсә икәнлеге аңлашыла. Тагын шунысы мөһим: барлык җитәкчеләребез дә – үзебезнең укучыларыбыз, үзебезнең авылдашларыбыз. Әнә шундый колхозыбызны Ветераннар советы ярдәмендә саклап калганбыз икән, илебез күләмендә беренче төзелгән Ветераннар советы белән горурланасы гына кала!

Зөфәр ДӘҮЛӘТШИН.
Тукай районы Иске Абдул авылы

88 ЯШЬЛЕК ӘБИНЕҢ КҮРШЕЛӘРЕ:

«ТУГАНЫБЫЗ КЕБЕК ЯКЫН»

Актаныш районының Чуракай авылында гомер итүче Хиффә Гаязованы интернетта күреп яратучылар, хәтта аңа дип әллә кайлардан бүләк җибәрүчеләр дә бар икән. Бервакыт әбекәйне күршесе Ирек Шәехов видеога төшереп ала да социаль челтәргә куя. Халык моны бик ярата. Иректән күреп, бу видеоны үзләренә дә алып куючылар табыла. Әнә шулай итеп, Ирекнең язылучылары, әбине яратучылар арта. Социаль челтәрләрдә әбине караучылар Иреккә бик рәхмәтле. Әмма егет үзе генә артык мактанмый, яхшы сүзләрне дә кабул итәргә ашыкмый. Әбекәйгә булышып яшәвен гадәти хәл дип аңлата.

– Максатым язылучы арттыру түгел иде. Хиффә әбине без гомер буе якын итәбез. Бабае моннан 20 еллар элек үлеп киткән аның. Әтиебез ташламады үзен. Гел ярдәм итеп торды. Аңа ияреп, без дә әбигә кереп йөри башладык. Ире белән озак еллар бергә яшәсәләр дә, балалары булмаган аларның, – ди Ирек. – Бер кайткач кердем дә, әби миңа тормышын сөйли башлады. Аны истәлеккә дип яздырып аласым килде. Аннары интернетка куясы иттем. Әнә шулай әбине яраттылар да инде. Кемдер аның җыйнак кына өен үз туган йортына охшата, кемдер үзенең әнисен, әбисен исенә төшерә.

Хиффә әбинең ире бик оста куллы була. Нинди генә эшкә тотынса да, шуны ялт итеп эшләп куя. Әбекәй дә зарланып, сукранып ята торганнардан түгел. Тугызынчы дистәне ваклап барса да, кызлар кебек әле. Йөрәге 18дә! Үзен дә бик карап кына яши, ди Ирек. Хиффә әби табиб кушкан даруны тиешле вакытында эчә икән. Кичтән пешергән ашны икенче көнгә кайнатып чыгармыйча ашамаска киңәш итә. Баксаң, җылытып кына алсаң, андый ризык ашказанына ярамый икән. Хиффә әби җәй буе үлән дә җыя, ди. Шуларны эчеп, әкренгә генә яшәп ята. Күңеле кор үзенең. Әле менә күптән түгел тау шуарга барганнар. Әбекәйнең үзенең чана шуасы килгән. Балачактагы кебек таудан шу идең, ди икән. Ирек аның бу теләгенә каршы килмәгән.

– Хиффә әбине күз карашыннан аңлыйм мин. Мин, әйдә тау шуабызмы, диюгә ризалашты. Күзләрендә ут яна. Яше генә зур. Үзе әле дә яшьлегендә ул. Гәүдәсе җиңел, тормышның ямен табып яши белә. Тау шудырганда курыктым да инде. Тюбингка утыртып төшереп җибәргәч, барысын да уйлыйсың. Видеода бөтенесен дә күрсәтеп бетереп булмый. Агачка бәрелә күрмәсен, дип тә кайгырдык. Яше дә бар бит инде, сөякләре сынар дип тә кот очты. Әмма теләгенә каршы килә алмадык, – ди Ирек.

Илдә мобилизация башлангач, Ирек интернетка күңелле видеолар кертми тора. Уңайсызландым, ди. Әмма шул вакытта Хиффә әбине югалтучылар күп була. Иреккә хатлар килә. Иреккә генә түгел, Хиффә әбинең үзенә дә, кая югалдың, диюче була. Баксаң, башка авылдашы белән Актанышка барган икән. Шунда 3–4 кеше танып алып, нигә сине интернетка куймый башладылар, дигән. Хиффә әби Иреккә шуларны кайтып әйткән. Әби фотога да, видеога да төшергәнгә ияләшеп беткән инде. Камераны тотып килә башлауга, тиз генә үзен рәтләп куя, елмаеп җибәрә икән.

– Хиффә апаны бик яратабыз без. Күрше генә түгел инде ул, бик якын туганыбызга әйләнде. Без – аңа, ул безгә бик ияләндек. Кайтканны белүгә, тәм-томнарын кыстырып кереп җитә. Бәйрәмгә күчтәнәчләр дә бирә. Кибеттән үзенә ни алса, безгә шуны кертә. Аның күңеле изге. Бөтен кеше дә Хиффә әби кебек була алмый, – ди Ирек. – Хиффә әбине хәзер дөньяның төрле почмакларында да беләләр. Әстерхан якларыннан, Владикавказдан да аңа дип посылкалар җибәрәләр. Туган нигезе беткән, кайтыр авылы булмаган кешеләр, Хиффә әбинең йортын, үзен күрсәткәч, бик җылы сүзләр язалар. Кемнедер балачагына, яшьлегенә кайтара алганыбызга бик сөенәбез.

Ирекнең генә түгел, аның әти-әнисенең дә игелекле кешеләр икәнен аңладык инде. Алар олы кешене матур яшәтергә тырышалар. Сәламәтлеген дә кайгырталар. Баксаң, Хиффә әбинең күзенә операция кирәк икән.

– Коронавирус башланганчы, бер күзенә операция ясатып кала алдык. Чир таралгач, икенчесенә өлгермәдек. Менә хәзер шул күзенә операция кирәк. Актанышка барып, чиратка да язылып кайткан идек. Әмма никтер чират селкенми әле. Әллә, олы кеше дип, артка калдыралар инде. Бер күзе начар күргәч, икенчесенә авырлык килә икән. Шуңа да операцияне тизләтергә иде, – ди Ирек.

Без исә Хиффә әбинең чиратын белешергә сүз бирдек.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Бер-береңне санлап яшәсәң, тормыш җиңел бара»

Апас районының Дәвеш авылында яшәүче Тәскирә апа һәм Камәртдин абый Хәйретдиновлар гаиләсе – авылның күрке. Бер-берсенә терәк, ышаныч, балаларына кайгыртучан әти-әни булып, күрше-күлән, туган-тумача, дус-ишләре арасында олы хөрмәткә ирешеп, 53 ел бергә гомер кичерә алар. Тырышлыклары, тату, булдыклы, гадел һәм гади булулары белән аерылып торалар. Үз урнәкләрендә 5 бала тәрбияләп үстергәннәр. Бүген 11 онык һәм 4 оныкчыклары өчен кадерле дәү әти, дәү әни булып яшиләр.

Камәртдин абый 40 елдан артык шофер булып эшли. Бүген ул дин юлында. Мәчеттә мәзин вазыйфасын башкара. Авылга моңлы азан тавышын яңгырата.

– Дәвеш мәктәбендә 8 классны тәмамлагач, колхозда ат җигеп эшли башладым. Аннан 3 ел армия сафларында хезмәт иттем. Соңыннан Буага шоферлыкка укырга киттем. Шушы еллар мине булачак хатыным белән таныштырды. Һындыр табагына эшкә йөрүче яшь, җитез, тыйнак кызны очраттым. Озак аралашмадык, кавыштык. Гомер буе тугрылык саклап, аңлашып яшәдек, – диде гаилә башлыгы.

Тәскирә апага кирпеч заводында, тавык фабрикасында эшләргә туры килә. Озак еллар фермада хезмәт итә, бозаулар карый, бозаулату бүлегендә эшли. «Ана даны» медаленә ия.

– Холкы әйбәт, беркайчан авыр сүз әйтми ул. Аңлашып яшибез, балалар кайтып йөри. Тыныч кына, бер-береңне санга сугып яшәсәң, тормыш җиңел бара. Каенана-каената белән яшәдек. Тормышыбызга сөенеп гомер итәбез, – ди Тәскирә апа.

Бүген дә Хәйретдиновлар тик кенә тормый. Алар ишегалды тутырып кошкорт асрый, йорт-җирләрен дә карап, пөхтәләп кенә торалар. Тәскирә апа оекбашлар, башмаклар бәйләп, балаларын, якыннарын сөендерергә ярата.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА.
Апас районы

ОНЫТЫЛМАСЛЫК БУЛДЫ

Күптән түгел Кавказга шифаханәгә юллама бирделәр. Юлымда гел әйбәт кешеләр очрады. Әлмәт шәһәреннән Нәҗибә белән 18 көн бергә яшәдек. Без Татарстаннан 50ләп кеше идек. Арча, Буа, Түбән Кама, Казан, Кукмара, Кайбыч, Менделеевск, Тәтеш, Теләче, Әлмәт, Зәй, Чаллы, Яшел Үзән... ветераннары дуслашып, татар-рус телләрендә сөйләшеп, матур итеп ял иттек, төрле процедуралар алдык, татарча биюләр, җырлар, экскурсияләр озак сакланачак истәлекләр булып калдылар.

Ял итүчеләр арасында кайдан гына инвалидлар, өлкәннәр, балалар юк иде. Кабардиннар – бик кунакчыл халык, чеченнәр күмәк ял итәләр, оста бииләр, матур сөйләшәләр, өлкән буынны хөрмәт итәләр, бисмилла әйтеп ашый башлыйлар, автобуста сикереп торып елмаеп урын бирәләр.

Нальчик шәһәре бик матур һәм чиста, бөтен җирдә тәртип. Институт, техникум, мәдәният учаклары күп. Без «Балкария» җыр-бию ансамбле концертына бардык.

Бу сәяхәт минем тормышны ямьләде, башкаларның ничек яшәвен күреп, уйланырга, кайвакыт тормышка карашны тамырдан үзгәртергә мәҗбүр итте. Чечен шарлавыгына экскурсия исемдә калды, сихерле таулар, көмеш су агышы бер фильмны хәтерләтте. Бу сәяхәтем онытылмаслык булды.

Илгизәр ТИМЕРГАЛИЕВА.
Менделеевск

ЧЫН ҖИР КЕШЕСЕ

Тормышның күп киртә-баскычларын үтеп, үзенең максатларына туктамый ирешеп барган хөрмәтле авылдашым ул Сәгадәтулла Төхбәтуллин. Бездән шактый ара үскәнгә күрә, гел үрнәк булды – урта мәктәпне тәмамлаганда мал да көткән, җир дә сөргән, комбайн да иярләгән чын ир иде.

Инде шул чакларда ук Ленин, Хезмәт Кызыл байрагы орденнары кавалеры туган абыйсы Мәхәсим Хәйруллин белән бөртек суктыруда республика күләмендә танылу алган алар. Үсеп җиткән төпчек малай, мәктәпне тәмамлауга ук, ишле гаиләләрен бөтәйтергә дип, Киров якларына урман кисәргә китеп бара. Анда ул авырлыклар алдында берчакта да югалып калмаслык чыныгу ала. Урман кисү булгач, кесә тутырырлык акча алып кайта һәм шул көздә абыйлары белән өй-ихаталарын ялт иттереп куялар. Аннары «Чирәм җирләрне үзләштерергә!» дигән комсомол чакыруы яңгырауга, Сәгадәтулла, атлыгып, Казахстан далаларына китеп бара. Әлбәттә, монысы хезмәт биографиясендә иң истә калырлык, чөнки менә анда аның тракторчы-комбайнчы һөнәрләреннән битәр, оештыру-туплау талантлары өскә калка. Бөтенләй икенче уй-хыяллар белән шуннан армиягә алына. Тормышның ыгы-зыгылы сынауларына тәмам күнеккән солдат гимнастеркалы егетебез, туган җирен сагыну хикмәтеннән, туры Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономлык факультетына укырга керә.

Шул вакытларда безнең кебек замандашлар күңеленә Сәгадәт абый булып кереп калды ул. Бу чорларда бит әле авылда яшьләрнең бик тулы, җанлы-күңелле чагы. Бүген катлы-катлы мәһабәт бинада башлангыч сыйныфы көчкә сакланып, берничә бала калган, ә ул укыганда иске генә агач мәктәптә 300дән дә артык укучы булган. Тирә-юньнән, ызандаш Башкортстаннан йөзәрләгән балаларны безнең әниләр кышын, язгы өзеклекләрдә интернатта тәрбияләп тоттылар. Сәгадәт абый исә институтта укыганда да мәктәбебезнең бик көтеп алган, яраткан кешесе иде. Үзе кебек таза бәдәнле студент дуслары белән кайталар да һөнәргә өйрәтү – җыргә, агрономлыкка тартылу буенча кызыклы кичә-дискуссияләр үткәрәләр. Күпме авылдашларын институтка тартып, дипломлы белгечләр итеп чыгарды ул! Аннары алар авылны җитәкләүчеләр-яшәтүчеләр булып киттеләр – менә ул турылыклы остазлык кайда!

Һәм иске агач клубта да Сәгадәт абыйлар бик тансык, анда алар оештырган кичәләргә күрше авыллардан да тикмәгә генә ябырылып агылмагандыр шул.

Авылдаш егетебезнең институтта тынгысызлыгын, оештыру-активлыгын, лидерлыгын тиз күреп алалар, профком, партком әгъзасы итеп сайлыйлар. Аңа диплом алганда укуын фәнни эшчәнлектә дәвам иттерергә, институтта җитәкчелектә калырга тәкъдим итәләр, ләкин Сәгадәтулланы ямьле Ык буйлары – әкияти туган җире һәрдаим үзенә тартып торгач, ул үз кыйбласына тугры кала. Язгы кояш нурлары иркәләгәндә кайтып төшә ул Тельман исемендәге колхоз басуларына. Алмачуар кебек уйнаклап торган киң бәдәнле чибәр егет, тирә-юньгә танылган председатель Мират агай Гыйлаҗетдинов белән очрашуга:

– Атларны сагынып кайттым, Мират абый! – дип эндәшә.

– Исәбең – җирдә эшләргәме? – дип, аны шунда ук Гыйлаҗетдинов атлар янына алып китә.

Малай чакларында, Урал тавы болынлыкларын иңләп, атлар көтеп йөргән Сәгадәтулла башта бер, аннары икенче чабышкыны җитәкләп ала, малкайлар да аны таныган кебек ябышып торалар.

Моңарчы гел машинада гына чапкан җитәкче-белгечләргә яшь агрономның һәркөнне болай атка атланып басудан басуга йөрүе гаҗәеп бер тамаша кебек була, билгеле. Язгы чәчүдә дә, кызу уракта да гел атта йөрер Сәгадәтулла. Менә алар башкорт якларына сузылган эре башаклы бодай кырында райкомның беренче секретаре Әнвәр Баһаветдинов белән очрашалар.

– Бу тиклем басуларны урап, атың арымыймы соң? – ди аңа район хуҗасы, шаяртып.

– Ат иярләгән кеше генә туган җирен ярата ала, бу – шундый егет! – дип кушыла аңа Мират ага.

Әлеге очрашуның ахыры шул була: берничә көннән Сәгадәтулла Рәхмәтулла улы Төхбәтуллинны район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы итеп куялар һәм шул җәһәттән райком бюросы әгъзасы да була ул. Үз чоры өчен авыл хуҗалыгындагы яшь белгечкә шундый җаваплы вазыйфаның ышанып тапшырылуы күпләр өчен көтелмәгән хәл була бу. Остазы Әнвәр абый ялгышмаган булып чыга, район иген уңышын күтәрүдә сизелерлек адымнар ясый. Әнвәр Баһаветдинов күпме җитәкче-белгечләрне сыный, тик арадан бик сирәкләре генә җир серләрен белеп, аңа ябышып калалар. Бу чорда басуларны солыча басып, зур уңыш алырга ирек бирми. Тәҗрибәле җир белгече Нияз Габитов белән карабодайның мәйданын киңәйтеп җибәргәч һәм инде сөрүлек җиренең 10 процентына җиткергәч, теге «кара солы» дигән чүп үләнне тәмам җиңеп чыгуга ирешәләр. Азнакай карабодае районның брендына әверелә, бер‑едә бөтенроссия семинары үткәрелеп, бөтен СССР күләмендәге белгеч-галимнәрне шуңа өйрәтәләр.

Булдыклы җитәкчене алда яңа биеклекләр көтә. Сәгадәтулла Төхбәтуллинны Питрәч райкомының – икенче секретаре, аннары Чүпрәле райкомының беренче секретаре итеп алалар. Бераздан Ютазы районын оештырып, партия райкомын җитәкли, бер елдан район башлыгы була. Алга таба – Ютазы элеваторы директоры, «Нур-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең оештыручы-җитәкчесе. Әле лаеклы ялга чыккач та, менә хәзер сигезенче дистәсен үткәч тә, Сәгадәтулла Рәхмәтулла улы – район башлыгы ярдәмчесе, үзенең бай оештыру-җитәкчелек итү тәҗрибәсен өйрәтү белән мәшгуль.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Югары Стәрле авылы

Укучылар иҗаты

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

БЕРНИ ОНЫТЫЛМЫЙ

– Киткән икән...
– Ул да киткәнмени?
– Яхшы иде... Авыр югалту.
– Иртә киткән... Оҗмахтадыр җаны...
– Чарасыздан күңел юату...
– Изге җаннар кыела да китә,
Нурлар чәчеп яшәр чагында.
– Иң шәпләре, яхшылары китә,
Гөнаһ тулы җаннар барында.
Язмыш-нәләт матур гомерләрне
Харап итә таптап нахакка.
Бакча тулы гөлләр арасыннан
Гүзәлләрен кисә сабакта.
Вакыт юа, күз яшьләре кибә,
Язмыш тигән эзләр сулкылдый.
Гомер уза, хәсрәт кими төшә,
Сагыш үтә – берни онытылмый.

ЧҮБЕКТӘН МАЙ ЧЫКМАС...

Бу арада кышкы төннәр озын,
Күзгә йокы керми йөдәтә.
Һәр борчылу зыян салып китә
«Дерт» итәргә торган йөрәккә.

Яңалыклар тыңламыйм да хәзер,
Үз җаема яшим дә кебек.
Яманы да, чыны, ялганы да
Кала һаман йөрәккә кереп.

Мин генәме шулай якын алам
Бу дөньяның даулаш, орышын?
Дөнья күчәрендә чүп кенә мин юкса,
Ни мәгънә бар, әйтик турысын.

Төкеримче бөтен борчуына,
Чүбектән май чыкмас, тәгаен.
Мин туганчы дөнья шундый булган,
Мин киткәч тә тынмас, мөгаен.

ИҢ ГАДЕЛ РОЛЬ

Тормыш сәхнәсендә артистлар без,
Чыра яккан чордан иске фикер.
Төрле битлек, төрле сурәт көндә,
Исәпләсәң, могҗиза ул, исең китәр.

Сукыр тиен тормас вак рольләр бар,
Итәк чабуына тиеп киткән.
Кайсылары мәңге кабатланмый,
Ни кызганыч, минем вакыт үткән.

Тормыш сәхнәсендә мизгел генә
Җиләк җыйган, көтү көткән чагым.
Балык кебек суда чумып йөзгән,
Чәчләремне тузгып көлгән чагым.

Болын иңләп чапкан гамьсез бала,
Сәю көткән гади керсез сылу...
Апа, сеңел, иптәш, хатын, хуҗабикә,
Иң газиз роль, шиксез, ана булу.

Һөнәр иясе дә саллы битлек,
Шәхес роле мөһим аннан кала.
Хәрәмләшми генә уйный алсаң,
Язмышыңның тотанагы алар.

Иң гадел роль тормыш сәхнәсендә.
Артист юкта, битлек салгач.
Бер ялгансыз...

Сания ВӘЛИУЛЛИНА

РӘХМӘТ, БӨРБАШ!

Шүрәле урманнарында
Бабаем урманчы булган.
Җиденче баласы булып
Минем әнием туган.

Тиф чирләре алып киткән
Әти белән әнисен.
Язмышыңа каршы килеп
Булмый шул ул, нишлисең.

Әниләргә авыр чакта
Ярдәм иткән күршеләр.
Яши икән бу авылда
Мәрхәмәтле кешеләр.

Сабый чакта әни китә
Асрамага, еракка.
Сәрдекбашка язмыш илтә,
Яшәргә бала чакта.

Яраталар ятим кызны,
Үстерәләр үз итеп.
Сокландыра егетләрне
Чибәр кыз, үсеп җитеп.

Сукмакта тора егетләр,
Көтеп, суга килгәнне.
Ә ул сайлый Чишмәбаштан
Батыр Фатыйх дигәнне.

Рәхмәт, Бөрбаш!
Син бит безгә
Бүләк иттең әнине.
Бәхетле булып яшәдек,
Булдык әти-әниле.



Табигать нигъмәте

Нарат җиләге



Төньяк җиләкләре арасында иң киң таралганы. Латин теленнән тәрҗемәдә ул «виноград тәлгәше» дигән мәгънәгә туры килә.

Нарат җиләген чи килеш тә, киптереп тә, пешереп тә ашыйлар. Ул – бик яхшы «табиб». Җиләк үтне кудыру, кан тамырларын ныгыту, йөрәк эшчәнлеген нормага салу үзлекләренә ия. Каротин күләме буенча нарат җиләге мүк җиләгеннән, лимон, груша, алма, кара җиләк һәм виноградны узып китә. Анда B_2 витамины да күп. Әлеге витамин ашказаны эшчәнлеген нормага сала, организмның тонусын күтәрә.

Кура җиләге

Аспиринны алыштыра ала. Ул салицил кислотасына бай. Ул ялкынсынуларга каршы көрәшә, тән температурасын төшерә. Шуңа да элек-электән салкын тигәндә кура җиләге белән чәй эчәргә кушалар. 2 аш кашыгы җиләкне 3/4 стакан кайнар суда 15–20 минут төнәтәләр, сөзәләр. Төнәтмәне кайнар килеш көнгә 2–3 мәртәбә 2шәр стакан эчәләр. Ютәл булганда төнәтмә ярдәмендә ингаляция ясарга мөмкин. Аны кайнатып чыгаралар һәм, баштан сөлге белән капланып, шуның парын сулыйлар. Процедураны көнгә 2–3 тапкыр һәм йоклар алдыннан ясыйлар.

Тамак төбе авыртса, кура җиләге серкәсе белән чайкаталар. 2 стакан җиләкне 2 стакан алма серкәсенә салалар. 10 көн җылы урында төнәткәч, сөзеп, стерильләштерелгән банкага тутыралар. Төнәтмәне суыткычта саклыйлар.

Тонзиллит кискенләшсә, авыз эчен кура җиләге согы белән чайкатырга киңәш ителә. Процедураны көнгә өч мәртәбә кабатлыйлар. Кура җиләге согы авыртуны баса, шешне бетерә.



ҖАВАПЛАР. Горизонталь буенча: карават, Уфа, рам, шкаф, чар, УЗИ, таш, мук, мәк, чит, дирһәм, даими, рикша, Сарман. **Вертикаль буенча:** кыршау, мич, дар, иза, ширкәт, ияк, мирас, фирка, умач, тимер, ала, батыр, шик, диван.

Кишер согы

Кишер согы бик файдалы. Ул бөтен организмны нормаль хәлгә китерә. Кишер суы B, C, Д, E, K витаминнарына бай, анда A витамины (организмга гаять файдалы, аеруча күзләр өчен) күп.

Организмга ничек тәэсир итә соң ул? Кишер согы аппетитны күтәрә, ашказаны-эчәк системасы эшчәнлеген, тешләр структурасын яхшырта. Йөкле хатын соңгы айларында көненә 300 мл кишер согы эчсә, бала тудырганда сепсис (кан агулану) булмый. Кишер согы эчкән хатынның сөте сыйфатлы була. Шунлыктан йөкле һәм имчәк баласы булган хатыннарга кишер согы эчәргә киңәш ителә.

Кишер согындагы матдәләр күзләрнең күрү сәләтен яхшырта. Шуңа күрә очучыларга, машина йөртүчеләргә, журналистларга һ.б. эчәргә кушалар.

Кишер согы төрле шешләрне (яман шешне дә) дәвалаганда әйбәт ярдәм итә. Тән тиресе коры булганда, гомумән, тире авыруларын дәвалаганда ул бик файдалы. Кишер согы эндокрин (эчке агъзалар) системасын дәвалый, аны ирләргә җенси көчсезлектән, хатыннарга бала тапмаганда кулланырга киңәш ителә.

Кишер согы кыйммәтле даруларны алмаштыра ала.

Кызыл миләш

Кызыл миләш дәвалау үзлекләренә ия. Мәсәлән, аның согын халык медицинасында атеросклерозны һәм гипертоник авыруларны дәвалау өчен файдаланалар. Миләш төнәтмәсе дизентерияне дәвалау өчен дә кулланыла. Ашказаны, эчәк авырулары вакытында аннан төнәтмә ясап эчәргә киңәш итәләр. Шулай ук миләш согы бөердән ташларны чыгару өчен дә файдаланыла. Моның өчен 400 г миләшне изәләр, аңа 2 литр кайнаган су һәм бераз шикәр комы салалар, дүрт сәгатьтән соң болгатып сөзәләр һәм эчәләр. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70–100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә. Ул бөердән ташларны чыгарырга да булыша. Табиблар исә диабет белән чирләгән авыруларга, бавыры авыртканнарга миләш ашарга куша.

Чөгендер

Йодның күплеге буенча чөгендер башка яшелчәләр арасында беренче урыннарның берсен алып тора. Шунлыктан чөгендерле азык атеросклероз белән интегүчеләргә бик файдалы. Чи чөгендер согын матдәләр алмашын яхшыртучы һәм организмны ныгытучы чара буларак эчәргә була. Пешкән чөгендер гипертония авыруларыннан да шифалы тәэсир итә, чөнки анда кан басымын төшерергә ярдәм итүче магний шактый күп. Халык медицинасында кан басымы югары булганда һәм тынычландыручы чара буларак, яртылаш бал белән кушылган чөгендер согы эчәләр (көнгә 3–4 тапкыр яртышар стакан). Томау төшкәндә, пешкән чөгендер согы белән борын эчен юалар. Ялкынсынуны йомшарту өчен, чөгендер боткасын вакыт-вакыт (кибүенә карап) җәрәхәтләргә һәм шешләргә куялар.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru